# Укыйм әле

Запись Масгуды Шамсутдиновой




Укыйм әле, укыйм әле

Укыйм әле, укыйм әле, күңелләрегез ачылсын,
Сигез оҗмах эчләрендә ризыкларыгыз чәчелсен.
Тәмам сөям үзегезне кабул итеп сүзегезне,
Бер Ходаем якты кыйлсын Кыяматтә йөзегезне.
Карасам йөзегез якты, сөйләгән сүзегез татлы,
Дөнья гизеп эзләсәм дә табылмас бу мәҗлес хәтле.
Мәҗлесләрнең кадрен белеп Ходайга күп зекер кылыйк,
Дин Исламда булганлыкка шатланышып шөкер кылыйк.
Утырмаек фикер беләң, утыраек зикер беләң,
Хуш нигъмәтләр хәзерләнгән, ашадык без шөкер беләң.
Мәҗлес хәзерләүчеләргә Ходаем рәхмәтен салсын,
Сират күпрен ансат кичеп җәннәт ишегенә барсын.
Мәҗлес җыйган хуҗаларның нурлы әйлә каберләрен,
Бу мәҗлесләр бик кадерле, бик беләек кадерләрен.
Безне зурладыгыз бүген зур мәҗлес хөрмәте берлән,
Җәннәт сезне каршы алсын Ходаның хөрмәте белән.
Мәҗлес ясап хәзерләгән - безнең өчен зур хөрмәтләр,
Рәсүлюлла сезгә кылсын Кыяматтә шәфәгатьләр.

Мәсгудә Шәмсетдинова архивыннан. 22 февраль, 2018 ел

©